РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 12 сентябре № 33

Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба – «Нигезләмә»):

Нигезләмәнең 10.3 пунктында «кимендә 2 ай һәм 4 айдан да артык түгел» сүзләрен «кимендә бер һәм өчтән дә артык түгел» сүзләренә алмаштырырга;

11.3, 15.1 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының Регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин